ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 183-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары И.И. Бикеев һәм А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 183-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 8 июне
№ 641-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы Дәүләт
Советы депутатлары
И.И.Бикеев һәм А.А. Чубаров
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш), № 75 (I өлеш); 2026, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $8^6$ пункт өстәргә:
«$8^6$) социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә, аларны мәҗбүри күченеп килүчеләр, качаклар дип тануга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирүгә яисә Россия Федерациясе гражданлыгына алуга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, аларны мәҗбүри күченеп килүчеләр, качаклар дип тану турында сораучы, мәҗбүри күченеп килүчеләр, качаклар булып танылган йә Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алган затлар;»;

2) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 22 пункт өстәргә:
«22) әлеге статьяның 1 өлешендәге $8^6$ пунктта күрсәтелгән затларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү, аларны мәҗбүри күченеп килүчеләр, качаклар дип тану, аларга Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү, аларны Россия Федерациясе гражданлыгына алу, юридик әһәмияткә ия булган фактларны билгеләү һәм әлеге мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле югалган документларны торгызу.»;

3) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:
«7) аларны мәҗбүри күченеп килүчеләр, качаклар дип тану турында сораучы, мәҗбүри күченеп килүчеләр, качаклар булып танылган йә Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алган затлар булсалар – юридик

әһәмияткә ия булган фактларны билгеләүгә һәм социаль ярдәм чаралары күрсәтү, мәҗбүри күченеп килүчеләр, качаклар дип тану, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү яисә Россия Федерациясе гражданлыгына алу өчен кирәкле югалган документларны торгызуга бәйле мәсьәләләр буенча.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерүгә юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Федераль законның 20 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 23 мартындагы 64-ФЗ номерлы Федераль закон белән дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия булган гражданнар категорияләре исемлеге киңәйтелә. Мондый хокук мәҗбүри күченеп килүчеләр, качаклар дип тану турында сораучы, мәҗбүри күченеп килүчеләр, качаклар булып танылган йә Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алган затларга бирелә, әгәр алар социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә, мәҗбүри күченеп килүчеләр, качаклар дип тануга, вакытлыча сыену урыны бирүгә яисә Россия Федерациясе гражданлыгына алуга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр,

Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы дәүләт юридик бюросы һәм адвокатлар мондый затларны мәҗбүри күченеп килүчеләр качаклар дип тану максатларында, вакытлыча сыену урыны биргәндә, Россия Федерациясе гражданлыгына алганда, шулай ук юридик әһәмияткә ия булган фактларны билгеләү һәм тиешле мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле югалган документларны торгызу кирәк булган очракларда хокукый консультация бирәләр һәм хокукый характердагы документлар төзегәндә ярдәм итәләр.

Бәян ителгәнгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының «Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия гражданнарның категорияләре һәм мондый ярдәмне күрсәтү очраклары» 12 статьясына тиешле үзгәрешләр кертелергә тиеш.

Закон проекты ике статьядан тора.

Закон проектының 1 статьясында 12 статьяга үзгәреш кертү күздә тотыла.

2 статьяда Татарстан Республикасы законының үз көченә керү тәртибе: рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керәчәк дип билгеләнә.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башка Татарстан Республикасы законнарын кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү «Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатларга хезмәт хакы түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 21 октябрендәге 774 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертүне таләп итәчәк.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында «Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар бүлеп бирүне таләп итми.